| | |
|---|---|
| СОВЕТ<br>НУРЛАТСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>НОРЛАТ<br>АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ<br>СОВЕТЫ |
| РЕШЕНИЕ<br>«04» сентябрь 2023ел | КАРАР<br>№126 |

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Норлат авыл җирлеге Советы карарларының үз көчләрен югалтуын тану хакында.

«Коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законы 12.1 статьясы, 4.2 өлеше, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Норлат авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Норлат авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Норлат авыл җирлеге Советы карарларын үз көчен югалткан дип танырга:

«Аерым категория затларга Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачу һәм аларга ия булу, кулдагы акча һәм кыймматләрне саклауны, чит ил финанс инструментларына ия булуны һәм (яки) алардан файдалануны тыю турында» 16 апрель 2016ел 39 номерлы карарын,

«Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Норлат авыл җирлеге Советының 2014 елның 4 ноябрендәге 181 номерлы карарга үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Советының 2015 елның 14 августындагы 229 номерлы карары.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Интернет челтәрендә Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы (http://zelenodolsk.tatarstan.ru бастырып чыгарырга һәм шулай ук түбәндәге адреслар буенча: Татарстан Республикасы, Зеленодольск районы, Норлат авылы, М.Фәйзуллин ур., 17 йорт («Идел Аръягы» ҮКС бинасы), Татарстан Республикасы, Зеленодольск районы, Норлат авылы, Гагарин ур., 46 йорт (җирлек администрациясе бинасы) мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

Норлат авыл җирлеге башлыгы И.М.Саттаров